| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2025 Кукмара ш. № 659

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 26 апрелендәге 350 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 26 апрелендәге 350 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге нигезләмә акт проектында, гамәлдәге норматив хокукый актларда эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган

нигезләмәләрне ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру, муниципаль норматив хокукый актларга (алга таба - норматив хокукый актлар) экспертиза үткәрү тәртибен билгели.»;

2. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**